МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ
БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

12.01.2015 №14-п

# Мишә елгасы бассейнында урнашкан су объектларының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Су кодексының 26, 65 статьялары, 2007 елның 24 июлендә кабул ителгән “Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында” №221-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, 2009 елның 10 гыйнварында кабул ителгән “Җирлектә су объектларының сусаклагыч чикләрен һәм яр буе саклагыч полосаларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында” №17 Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, 2014 елның 3 февралендә кабул ителгән “Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт күчемсез милек кадастрына белешмәләр кертү өчен кирәкле булган документларны күчемсез милеккә хокукларны һәм аңа карата алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу, кадастр исәбенә алу һәм күчемсез милекнең дәүләт кадастрын алып бару өлкәсендә вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына җибәрү кагыйдәләрен раслау турында, шулай ук мондый документларның электрон рәвештәге форматына карата таләпләр турында” №71 Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, Россия Федерациясе Табигать министрлыгының 2010 елның 29 сентябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан федераль милектә булган һәм Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан су объектларын яки аларның өлешләрен саклау буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында” №425 Боерыгы, 2005 елның 6 июлендә кабул ителгән “Татарстан Республикасының Экология һәм

табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре” хакында №325 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан су мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен башкаруга субвенцияләр бирү турында 14.03.2014 ел, №МТ-54/36 килешү һәм 04.03.2013 ел, №13 МЭ-2ф “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Мишә елгасының һәм аның кушылдыкларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклагыч полосаларын билгеләү” турындагы Дәүләт контракты кысаларында башкарылган эшләрнең нәтиҗәләре нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә, №1 кушымта буенча, әлеге чикләрдә башкарылучы хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлекнең махсус тәртибен исәпкә алып, су объектларының су саклау зонасының һәм яр буе саклык полосаларының киңлеген билгеләргә.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А. Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрының беренче урынбасары Р.И Камаловка йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров

№1 кушымта

## Мишә елгасы бассейнында урнашкан су объектларының су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары

| № п/п | Су объекты | Су саклау зонасы киңлеге, м | Яр буе саклык полосасы киңлеге |
|---|---|---|---|
| 1 | Сеинка елгасы | 100 | яр 3 һәм аннан да күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр 3 градустан кимрәк авышлыклы булганда – 40 м. |
| 2 | Норма елгасы | 100 | яр 3 һәм аннан да күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр 3 градустан кимрәк авышлыклы булганда – 40 м; кирегә таба авышлыкта – 30м. |
| 3 | Щира елгасы | 100 | яр 3 һәм аннан да күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр 3 градустан кимрәк авышлыклы булганда – 40 м; кирегә таба авышлыкта – 30м. |
| 4 | Үшнә елгасы | 100 | яр 3 һәм аннан да күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр 3 градустан кимрәк авышлыклы булганда – 40 м; кирегә таба авышлыкта – 30м. |
| 5 | Иинка елгасы | 100 | яр 3 һәм аннан да күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр 3 градустан кимрәк авышлыклы булганда – 40 м. |
| 6 | Сулы елгасы | 100 | яр 3 һәм аннан да күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр 3 градустан кимрәк авышлыклы булганда – 40 м; кирегә таба авышлыкта – 30м. |
| 7 | Шемелка елгасы | 100 | яр 3 һәм аннан да күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр 3 градустан кимрәк авышлыклы булганда – 40 м. |
| 8 | Бима авылыннан чыгучы исемсез елга | 100 | яр 3 һәм аннан да күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр 3 градустан кимрәк авышлыклы булганда – 40 м; кирегә таба авышлыкта – 30м. |
| 9 | Бырыс елгасы | 100 | яр 3 һәм аннан да күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр 3 градустан кимрәк авышлыклы булганда – 40 м. |